**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об учреждении Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии

В целях дальнейшего развития химической науки в Республике Татарстан, поощрения ученых за выдающиеся научные труды, научные открытия и изобретения в области органической химии и увековечения памяти русского химика, представителя Казанской химической школы Владимира Васильевича Марковникова **постановляю**:

1. Учредить Международную премию имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии, присуждаемую один раз в два года, начиная с 2020 года.

2. Образовать Комитет по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии.

3. Утвердить:

Положение о Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (приложение № 1);

Положение о Комитете по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (приложение № 2);

состав Комитета по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (приложение № 3);

описание и рисунок медали «Лауреат Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии» (приложение № 4);

описание и образец бланка диплома лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (приложение № 5).

4. Кабинету Министров Республики Татарстан начиная с 2020 года обеспечить выделение Академии наук Республики Татарстан средств из бюджета Республики Татарстан на финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа.

5. Внести в перечень премий за выдающиеся достижения в области науки и техники, образования, культуры, литературы и искусства, средств массовой информации, суммы которых, получаемые налогоплательщиками, не подлежат налогообложению, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 3 декабря 2007 года № УП-651 «Об утверждении перечня премий за выдающиеся достижения в области науки и техники, образования, культуры, литературы и искусства, средств массовой информации, суммы которых, получаемые налогоплательщиками, не подлежат налогообложению» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 сентября 2014 года № УП-913, от 1 ноября 2014 года № УП-1014, от 7 ноября 2014 года № УП-1019, от 14 марта 2016 года № УП-240 и от 26 декабря 2017 года № УП-1169), изменение, дополнив его пунктом 10 следующего содержания:

«10. Международная премия имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии.».

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 июля 2020 года
№ УП-453

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июля 2020 года

№ УП-453

**Положение**
**о Международной премии имени В.В. Марковникова**
**за выдающийся вклад в области органической химии**

1. Международная премия имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (далее – Международная премия) учреждена в целях поощрения российских или иностранных ученых за выдающиеся научные труды, научные открытия и изобретения в области органической химии и увековечения памяти русского химика, представителя Казанской химической школы Владимира Васильевича Марковникова.

2. Международная премия присуждается Президентом Республики Татарстан один раз в два года к 13 декабря.

3. Международная премия присуждается одному российскому или иностранному ученому персонально за отдельные научные труды, научные открытия и изобретения, а также за их совокупность.

4. На соискание Международной премии представляются работы или комплекс работ единой тематики.

5. Международная премия посмертно или повторно не присуждается.

6. Лицам, удостоенным Международной премии, присваивается звание «Лауреат Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии», вручаются диплом, медаль и денежные средства (в российских рублях) в размере, эквивалентном 5 000 долларов США на день издания указа Президента Республики Татарстан об учреждении Международной премии.

7. Финансовое обеспечение затрат, связанных с вручением Международной премии, осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан.

8. Предложения о присуждении Международной премии вносятся органами государственной власти, российскими, иностранными и международными научными организациями, образовательными организациями высшего образования и иными организациями на рассмотрение Комитета по присуждению Международной премии (далее – Комитет) в срок до 1 сентября года, в котором присуждается Международная премия.

9. Предварительное рассмотрение и отбор научных трудов, научных

открытий и изобретений кандидатов на присуждение Международной премии осуществляются Комитетом в срок до 1 октября года, в котором присуждается Международная премия.

10. Выбор кандидата на присуждение Международной премии осуществляется Комитетом в срок до 1 ноября года, в котором присуждается Международная премия.

11. Предложение о присуждении Международной премии вносится Комитетом на рассмотрение Президента Республики Татарстан в срок до 10 ноября года, в котором присуждается Международная премия.

12. Обеспечение изготовления дипломов, медалей, а также организационно-техническое обеспечение подготовки и проведения церемонии вручения Международной премии осуществляется Академией наук Республики Татарстан.

13. Вручение диплома, медали и денежных средств производится Президентом Республики Татарстан или уполномоченным им лицом.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июля 2020 года

№ УП-453

**Положение**
**о Комитете по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии**

1. Комитет по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (далее – Комитет) образован в целях рассмотрения вопросов, касающихся подготовки предложений Президенту Республики Татарстан о присуждении Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (далее – Международная премия).

2. Состав Комитета утверждается Президентом Республики Татарстан.

3. На Комитет возлагается:

а) предварительное рассмотрение и отбор научных трудов, научных открытий и изобретений в области органической химии;

б) определение кандидата на присуждение Международной премии;

в) внесение Президенту Республики Татарстан предложения о присуждении Международной премии.

4. Комитет вправе привлекать в установленном порядке к рецензированию и экспертизе отобранных работ на безвозмездной основе специалистов в области химических наук, а также научно-исследовательские организации, образовательные организации высшего образования и иные организации.

5. Состав Комитета формируется из представителей органов государственной власти, образовательных организаций высшего образования, научных и иных организаций.

6. В состав Комитета входят председатель, заместители председателя, секретарь и члены Комитета, осуществляющие свою деятельность на общественных началах.

7. Руководство Комитетом осуществляется председателем Комитета. В период отсутствия председателя Комитета его обязанности по поручению председателя Комитета исполняет один из его заместителей.

8. Председатель Комитета планирует работу Комитета, назначает и ведет заседания Комитета.

9. Секретарь Комитета с правом совещательного голоса осуществляет

организационную и техническую работу по подготовке и проведению заседаний Комитета, в том числе проверку представляемых на рассмотрение Комитета документов (сведений), а также по результатам заседания Комитета готовит протокол.

10. Заседания Комитета проводятся по мере необходимости и считаются правомочными, если в них принимают участие более половины от общего числа членов Комитета.

11. Решение Комитета считается принятым, если за него проголосовали более половины членов Комитета, присутствующих на заседании. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании Комитета является решающим.

12. Решение об определении кандидата на присуждение Международной премии принимается путем тайного голосования не менее двумя третями голосов присутствующих на заседании членов Комитета в сроки, установленные Положением о Международной премии.

13. Решение Комитета оформляется протоколом, который подписывается секретарем Комитета и утверждается председательствующим на заседании Комитета.

14. Организационно-техническое обеспечение деятельности Комитета осуществляется Академией наук Республики Татарстан.

___________

Приложение № 3
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июля 2020 года

№ УП-453

**Состав**
**Комитета по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, председатель Комитета |
| Гафуров Ильшат Рафкатович | ректор Казанского (Приволжского) федерального университета, заместитель председателя Комитета (по согласованию) |
| Салахов Мякзюм Халимулович | президент Академии наук Республики Татарстан, заместитель председателя Комитета (по согласованию) |
| Соловьева Светлана Евгеньевна | ведущий научный сотрудник Института органической и физической химии им. А.Е. Арбузова – обособленного структурного подразделения Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», секретарь Комитета (по согласованию) |
| Анаников Валентин Павлович | заведующий отделом структурных исследований, заведующий лабораторией металлокомплексных и наноразмерных катализаторов Института органической химии им. Н.Д. Зелинского Российской академии наук, академик Российской академии наук (по согласованию) |
| Антипин Игорь Сергеевич | заведующий кафедрой органической химии Химического института им. А.М. Бутлерова Казанского (Приволжского) федерального университета, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Балова<br>Ирина Анатольевна | директор Института химии Санкт-Петербургского государственного университета (по согласованию) |
| Белецкая<br>Ирина Петровна | заведующий лабораторией элементоорганических соединений химического факультета Московского государственного университета имени М.В. Ломоносова, академик Российской академии наук (по согласованию) |
| Бурганов<br>Рафис Тимерханович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки Республики Татарстан |
| Галкин<br>Владимир Иванович | директор Химического института им. А.М. Бутлерова Казанского (Приволжского) федерального университета (по согласованию) |
| Джемилев<br>Усеин Меметович | научный руководитель Института нефтехимии и катализа Уфимского федерального исследовательского центра Российской академии наук, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |
| Егоров<br>Михаил Петрович | директор Института органической химии им. Н.Д. Зелинского Российской академии наук, академик-секретарь Отделения химии и наук о материалах Российской академии наук, академик Российской академии наук (по согласованию) |
| Коновалов<br>Александр Иванович | член Президиума Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», академик Российской академии наук (по согласованию) |
| Миронов<br>Владимир Федорович | заведующий лабораторией Института органической и физической химии им. А.Е. Арбузова – обособленного структурного подразделения Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |
| Ненайденко<br>Валентин Георгиевич | заведующий кафедрой органической химии химического факультета Московского государственного университета имени М.В. Ломоносова (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Салахутдинов Нариман Фаридович | руководитель отдела медицинской химии Новосибирского института органической химии им. Н.Н. Ворожцова Сибирского отделения Российской академии наук, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |
| Салоутин Виктор Иванович | заместитель директора по научной работе Института органического синтеза им. И.Я. Постовского Уральского отделения Российской академии наук, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |
| Синяшин Олег Герольдович | директор Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», академик Российской академии наук (по согласованию) |
| Федюшкин Игорь Леонидович | директор Института металлоорганической химии им. Г.А. Разуваева Российской академии наук, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию) |

Приложение № 4
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июля 2020 года

№ УП-453

**Описание и рисунок медали «Лауреат Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии»**

Медаль «Лауреат Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии» изготавливается из металла с покрытием темно-золотистого цвета и имеет форму круга диаметром 32 мм.

На лицевой стороне медали по центру изображен портрет русского химика, представителя Казанской химической школы Владимира Васильевича Марковникова, в верхней части по окружности – надпись на английском языке «Vladimir Markovnikov 1837–1904».

На оборотной стороне медали: в центре – химическая символика, обозначающая правило в органической химии, сформулированное В.В. Марковниковым, в верхней части – надпись на английском языке «KAZAN», в нижней части – цифры «1869».

Все изображения и надписи на медали рельефные.

Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с четырехугольной колодкой, обтянутой шелковой лентой красного цвета. Ширина колодки – 26 мм, высота – 15 мм. Ширина ленты – 23,5 мм, высота – 12,6 мм.

Медаль находится в футляре.






Приложение № 5
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «25» июля 2020 года

№ УП-453

**Описание и образец бланка диплома лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии**

Бланк диплома лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии печатается на мелованной бумаге плотностью 100 г/кв.м, которая содержит 25% хлопкового волокна, без оптического отбеливателя.

Бланк диплома представляет собой лист формата А4 (210 мм × 297 мм), расположенный вертикально, цветовой фон которого белый.

По центру бланка диплома располагается выполненная черным цветом (шрифт Times New Roman Italic, кегль 14 п.) надпись на трех языках – татарском, русском и английском:

***«ДИПЛОМ***
*лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова*
*за выдающийся вклад в области органической химии*

*Указом Президента Республики Татарстан*
*Международная премия имени В.В. Марковникова _____ года*
*присуждена*
*_____________________________________________________».*

Ниже надписи располагается подпись, выполненная на трех языках – татарском, русском и английском, которая состоит из слов «Президент Республики Татарстан», инициала имени, инициала отчества и фамилии Президента Республики Татарстан.

***Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен***
***В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты***
***ДИПЛОМЫ***

***Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә***
***_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия***

______________________________________________________

***бирелде***

*****

***ДИПЛОМ***
***лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова***
***за выдающийся вклад в области органической химии***

***Указом Президента Республики Татарстан***
***Международная премия имени В.В. Марковникова _____ года***
***присуждена***

______________________________________________________

*****

20___ INTERNATIONAL VLADIMIR MARKOVNIKOV AWARD
CERTIFICATE

*is presented to*

______________________________________________________

*for outstanding contributions in the field of organic chemistry*

*by the Decree of the President of the Republic of Tatarstan*

| | |
|---|---|
| *Татарстан Республикасы Президенты* | *Р.Н. Миңнеханов* |
| *Президент Республики Татарстан* | *Р.Н. Минниханов* |
| *President of the Republic of Tatarstan* | *Rustam Minnikhanov* |

__________

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында**

Татарстан Республикасында киләчәктә дә химия фәнен үстерү, галимнәрне органик химия өлкәсендә күренекле фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары өчен бүләкләү һәм рус химигы, Казан химия мәктәбе вәкиле Владимир Васильевич Марковников истәлеген мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. 2020 елдан башлап, ике елга бер тапкыр бирелә торган Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне гамәлгә куярга.

2. Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитетын оештырырга.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты составын (3 нче кушымта);

«Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты» медале тасвирламасын һәм сурәтен (4 нче кушымта);

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты дипломы бланкы тасвирламасын һәм үрнәген (5 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2020 елдан Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Указны гамәлгә ашыру белән

бәйле чыгымнарны финанслауга Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә акча күчерүне тәэмин итәргә.

5. «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы, 2014 елның 7 ноябрендәге ПУ-1019 номерлы, 2016 елның 14 мартындагы ПУ-240 номерлы һәм 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1169 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«10. Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия.».

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 25 июль
№ ПУ-453

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 25 » июлендәге
ПУ- 453 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен**
**В.В. Марковников исемендәге халыкара премия турында нигезләмә**

1. Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия (алга таба – Халыкара премия) Россия һәм чит ил галимнәрен органик химия өлкәсендә күренекле фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары өчен бүләкләү һәм рус химигы, Казан химия мәктәбе вәкиле Владимир Васильевич Марковников истәлеген мәңгеләштерү максатларында гамәлгә куелды.

2. Халыкара премия ике елга бер тапкыр 13 декабрьдә Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә тапшырыла.

3. Халыкара премия Россиядән яки чит илләрдән бер галимгә аерым фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары, шулай ук аларның җыелмасы өчен шәхсән тапшырыла.

4. Халыкара премиягә аерым авторларның бердәй тематикалы эшләре яисә эшләр комплексы тәкъдим ителә.

5. Халыкара премия вафат булган кешегә яки бер үк кешегә кабаттан тапшырылмый.

6. Халыкара премиягә лаек булган затларга «Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты» дигән исем, диплом, медаль һәм Халыкара премияне гамәлгә кую турында указ чыгарылган көнгә 5 000 АКШ долларына тигез күләмдә акча (Россия акчасында) бирелә.

7. Халыкара премия тапшыруга тотылачак чыгымнарны акчалата тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты хисабыннан башкарыла.

8. Халыкара премия бирү турында тәкъдимнәр Халыкара премия тапшырылачак елның 1 сентябренә кадәр дәүләт хакимияте органнары, Россиянең, чит илләрнең фәнни оешмалары һәм халыкара фәнни оешмалар, югары белем бирү оешмалары һәм башка оешмалар тарафыннан Халыкара премия бирү комитетына (алга таба – Комитет) карау өчен тапшырыла.

9. Халыкара премия тапшыруга кандидатларның фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап табулары Комитет тарафыннан Халыкара премия тапшырылачак елның 1 октябренә кадәр алдан карап тикшерелә һәм сайлап алына.

10. Халыкара премияне тапшыруга кандидат Комитет тарафыннан Халыкара премия тапшырылачак елның 1 ноябренә кадәр сайлап алына.

11. Халыкара премия тапшыру турында тәкъдим Комитет тарафыннан Халыкара премия тапшырылачак елның 10 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Президентына карау өчен бирелә.

12. Дипломнар, медальләр эшләү, шулай ук Халыкара премия тапшыру тантанасын әзерләүне һәм уздыруны оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан башкарыла.

13. Дипломны, медальне һәм акчаны Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән зат тапшыра.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «25» июлендәге
ПУ-453 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмә**

1. Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасы Президентына Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне тапшыру турында тәкъдимнәр әзерләү белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү максатларында төзелде.

2. Комитет составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

3. Комитетка түбәндәгеләр йөкләнә:

а) органик химия өлкәсендәге фәнни хезмәтләрне, фәнни ачышларны һәм уйлап табуларны башлангыч карап тикшерү һәм сайлап алу;

б) Халыкара премия тапшыруга кандидатны билгеләү;

в) Татарстан Республикасы Президентына Халыкара премия тапшыру турында тәкъдим кертү.

4. Комитет сайлап алынган эшләрне рецензияләү һәм аларга экспертиза үткәрү өчен түләүсез нигездә химия фәннәре өлкәсе белгечләрен, шулай ук фәнни-тикшеренү оешмаларын, югары белем бирү мәгариф оешмаларын һәм башка оешмаларны билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә хокуклы.

5. Комитет составы дәүләт хакимияте органнары, югары белем бирү мәгариф оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләреннән төзелә.

6. Комитет составына рәис, рәис урынбасарлары, секретарь һәм Комитет әгъзалары керә, алар җәмәгать башлангычларында эшли.

7. Комитетка Комитет рәисе җитәкчелек итә. Комитет рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комитет рәисе кушуы буенча аның урынбасарларыннан берсе башкара.

8. Комитет рәисе Комитет эшен планлаштыра, Комитет утырышларын билгели һәм алып бара.

9. Утырышта тавыш бирү хокукы булган Комитет секретаре Комитет утырышларын әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле оештыру һәм техник эшләрне башкара, шул исәптән Комитетка карауга кертелгән документларны (мәгълүматларны) тикшерә, шулай ук Комитет утырышы йомгаклары буенча беркетмә әзерли.

10. Комитет утырышлары кирәк булган саен үткәрелә һәм анда Комитет әгъзалары гомуми санының яртысыннан артыгы катнашкан очракта гамәлгә хокуклы санала.

11. Комитет карары, утырышта катнашучы Комитет әгъзаларының яртысыннан артыгы аны хуплап тавыш биргән очракта, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез бүленгән очракта, Комитет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.

12. Халыкара премия тапшыруга кандидатны билгеләү турында карар Халыкара премия турында нигезләмәдә билгеләнгән вакыт эчендә утырышта катнашучы Комитет әгъзаларының кимендә өчтән икесенең яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

13. Комитет карары Комитет секретаре кул куя һәм Комитет утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

14. Комитет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 25 » июлендәге
ПУ- 453 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен**
**В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты**
**составы**

| | |
|---|---|
| Песошин<br>Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комитет рәисе |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәлахов<br>Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Соловьева<br>Светлана Евгеньевна | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге аерымланган структур бүлекчәсе – А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты әйдәүче фәнни хезмәткәре, Комитет секретаре (килешү буенча) |
| Анаников<br>Валентин Павлович | Россия фәннәр академиясенең Н.Д. Зелинский исемендәге Органик химия институтының структур тикшеренүләр бүлеге мөдире, металл комплекслы һәм нанокүләмле катализаторлар лабораториясе мөдире, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Антипин<br>Игорь Сергеевич | Казан (Идел буе) федераль университетының А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты органик химия кафедрасы мөдире, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Балова<br>Ирина Анатольевна | Санкт-Петербург дәүләт университетының Химия институты директоры (килешү буенча) |
| Белецкая<br>Ирина Петровна | М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының химия факультеты элемент-органик кушылмалар лабораториясе мөдире, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Борһанов<br>Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Галкин<br>Владимир Иванович | Казан (Идел буе) федераль университетының А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты директоры (килешү буенча) |
| Җәмилов<br>Госәен Мәмәт улы | Россия фәннәр академиясенең Уфа федераль тикшеренү үзәге Нефть химиясе һәм катализ институты фәнни җитәкчесе, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |
| Егоров<br>Михаил Петрович | Россия фәннәр академиясенең Н.Д. Зелинский исемендәге Органик химия институты директоры, Россия фәннәр академиясенең Химия һәм материаллар турында фәннәр бүлекчәсе академик-секретаре, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Коновалов<br>Александр Иванович | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге президиумы әгъзасы, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Миронов<br>Владимир Федорович | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге аерымланган структур бүлекчәсе – А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты лабораториясе мөдире, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ненайденко<br>Валентин Георгиевич | М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының химия факультеты органик химия кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Сәлахетдинов<br>Нариман Фәрит улы | Россия фәннәр академиясенең Себер бүлекчәсе Н.Н. Ворожцов исемендәге Новосибирск органик химия институты медицина химиясе бүлеге җитәкчесе, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |
| Салоутин<br>Виктор Иванович | Россия фәннәр академиясенең Урал бүлекчәсе И.Я. Постовский исемендәге Органик синтез институты директорының фәнни эш буенча урынбасары, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |
| Синяшин<br>Олег Герольдович | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге директоры, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |
| Федюшкин<br>Игорь Леонидович | Россия фәннәр академиясенең Г.А. Разуваев исемендәге Металл-органик химия институты директоры, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча) |

___

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «25» июлендәге
ПУ-453 номерлы Указына
4 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты» медале тасвирламасы һәм сурәте**

«Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты» медале куе алтынсу төстәге металлдан коелган йөзлекле 32 мм диаметрлы түгәрәк формасында була.

Медальнең алгы ягында уртада рус химигы, Казан химия мәктәбе вәкиле Владимир Васильевич Марковников портреты төшерелгән, өске өлешендә – әйләнә буйлап инглиз телендә «Vladimir Markovnikov 1837–1904» дигән язма.

Медальнең икенче ягында уртада – В.В. Морковников тарафыннан төзелгән, органик химиядә кагыйдәне аңлатучы химик символика, ә өске өлешендә – инглиз телендә «KAZAN» дигән язма, аскы өлешендә – «1869» саннары төшерелгән.

Медальнең бөтен сурәтләре һәм язмалары рельефлы.

Медаль кызыл ефәк тасма белән тышланган дүртпочмаклы колодкага элмәк һәм божра ярдәмендә беркетелә. Колодканың киңлеге – 26 мм, биеклеге – 15 мм. Тасманың киңлеге – 23,5 мм, биеклеге – 12,6 мм.

Медаль футлярга салынган.







___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «25» июлендәге
ПУ-453 номерлы Указына
5 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты дипломы бланкы тасвирламасы һәм үрнәге**

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты дипломы бланкы тыгызлыгы 100 г/кв.м булган, 25% мамык җепселле, оптик агартылмаган югары сыйфатлы кәгазьгә басыла.

Диплом бланкы А4 (210 мм × 297 мм) форматтагы, вертикаль урнаштырылган кәгазь бите рәвешендә була, фоны ак төстә.

Диплом бланкының уртасында өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә (Times New Roman Italic шрифты белән, 14 п. кегльдә) кара төстәге язма урнаштырылган:

*Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен*
*В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә*
*_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия*
*_________________________________________ бирелде».*

Язмадан астарак өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә имза урнаштырылган, ул «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән, Татарстан Республикасы Президентының исеме инициалыннан, атасының исеме инициалыннан һәм фамилиясеннән тора.

*Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен*
*В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә*
*_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия*
*________________________________________________ бирелде*

*****

***ДИПЛОМ***
*лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова*
*за выдающийся вклад в области органической химии*

*Указом Президента Республики Татарстан*
*Международная премия имени В.В. Марковникова _____ года*
*присуждена*

_______________________________________________________

*****

20___ INTERNATIONAL VLADIMIR MARKOVNIKOV AWARD
CERTIFICATE

*is presented to*

_______________________________________________________

*for outstanding contributions in the field of organic chemistry*

*by the Decree of the President of the Republic of Tatarstan*

| | |
|---|---|
| *Татарстан Республикасы Президенты* | *Р.Н. Миңнеханов* |
| *Президент Республики Татарстан* | *Р.Н. Минниханов* |
| *President of the Republic of Tatarstan* | *Rustam Minnikhanov* |